**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 27 гыйнварындагы 219 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 31 мартындагы 974 номерлы карары белән расланган Вишневка торак массивыннан көнчыгыштарак урнашкан территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьяларына туры китереп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 31 мартындагы 974 номерлы карары белән расланган Вишневка торак массивыннан көнчыгыштарак урнашкан территорияне планлаштыру проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 апрелендәге 1497 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге механизм карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материал) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 27 гыйнварындагы
219 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 31 мартындагы 974 номерлы карары белән расланган**
**Вишневка торак массивыннан көнчыгыштарак урнашкан территорияне**
**планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. I «Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы» бүлегендә:

1.1. кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру сызымы фрагментын, әлеге үзгәрешләргә 2 номерлы кушымта нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге кушымтасы белән тулыландырып, әлеге үзгәрешләргә 1 номерлы кушымта нигезендә редакцияләргә;

1.2. кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру сызымындагы 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 таблица

| Билгеләнеше | Атамасы |
|---|---|
| ЖД1 | Күпкатлы торак төзелеше |
| ЖД2 | Күпкатлы торак төзелеше |
| ЖД3 | Күпкатлы торак төзелеше |
| ОУ1, III | 1224 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы |
| ДС2, II | 220 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы |
| И1, IX | Инженерлык-техник объектлар |
| ПЖ1 | Перспективалы торак төзелеше |
| ПЖ2 | Перспективалы торак төзелеше |
| XI | Паркинг |
| XII | Паркинг» |

1.3. кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру сызымындагы 2 таблицаны төшереп калдырырга.

2. II «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру турында, шулай ук территорияне план буенча үстерүнең характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә:

2.1. 2 пунктта:

2.1.1. 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

| «№ т/б | Атамасы | Берәмлек. | Саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Перспективалы төзелеш территориясе | га | 13,56 |
| 2 | Торак фондының гомуми мәйданы (ЖД1-ЖД3 зоналары өчен), шул исәптән: | кв.м | 121030 |
| 2.1 | ЖД1 зонасы өчен | кв.м | 54350 |
| 2.2 | ЖД2 зонасы өчен | кв.м | 47430 |
| 2.3 | ЖД3 зонасы өчен | кв.м | 19250 |
| 3 | Халык саны (ЖД1-ЖД3 зоналары өчен) | кеше | 4035 |
| 4 | Торак белән тәэмин ителеш | кв.м/ кеше | 30 |
| 5 | Коммерция биналары мәйданы (ЖД1-ЖД3 зоналары өчен), шул исәптән: | кв.м | 23480 |
| 5.1 | ЖД1 зонасы өчен | кв.м | 6079 |
| 5.2 | ЖД2 зонасы өчен | кв.м | 3287 |
| 5.3 | ЖД3 зонасы өчен | кв.м | 1000 |
| 6 | Торак фонды тыгызлыгы | мең кв.м/га | 9,5 |
| 7 | Кызыл линияләрдә урам-юл челтәренең озынлыгы | км | 1,14 |
| 8 | Торак йортларда катларның максималь саны | катлар саны | 14 |
| Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары | | | |
| 9 | Күпкатлы торак төзелеше | га | 17,30 |
| 10 | Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге | га | 2,43 |
| 11 | Сәламәтлек саклау объектлары | га | 0,63 |
| 12 | Белем бирү оешмалары | га | 0,86 |
| 13 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | га | 2,29 |
| 14 | Инженерлык-техник объектлар | га | 0,65 |
| 15 | Мәктәпләр | га | 3,31 |
| 16 | Балалар бакчалары | га | 0,85 |
| 17 | Урам-юл челтәре | га | 3,15» |

2.1.2. 1 таблицадан соңгы абзацта «ЖД1-ЖД-4» сүзләрен «ЖД1-ЖД3» сүзләре белән алыштырырга;

2.1.3. 2 таблицага кадәр түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сәламәтлек саклау объектларын план буенча урнаштыру зонасында (3 номерлы зона) поликлиника урнаштыру каралган.

Иҗтимагый-эшлекле билгеләнештәге объектларны план буенча урнаштыру зонасында (7 номерлы зона) 4 постка исәпләнгән янгын сүндерү депосы урнаштыру каралган»;

2.1.4. 2 таблицага өченче искәрмәдә «бер сменага 315 кеше кабул итүгә исәпләнгән өлкәннәр бүлеге һәм бер сменага 105 кеше кабул итүгә исәпләнгән балалар бүлеге булган амбулатория» сүзләрен «поликлиника» сүзе белән алыштырырга;

2.1.5. 2 таблицага искәрмәләрдән соң икенче абзацны төшереп калдырырга;

2.2. 3 пунктта өченче абзацны төшереп калдырырга;

2.3. 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Газ белән тәэмин итү БМК-1 блоклы модульле котельныйдан планлаштырыла. Газ куллана торган җиһазларны тоташтыруга «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖ тарафыннан бирелгән техник шартлар нигезендә тоташтыру ноктасы – диаметры 1200 мм булган югары басымлы газүткәргеч. Газ белән тәэмин итү буенча түбәндәге чаралар планлаштырыла:

- тоташтыру ноктасыннан проектлаштыру территориясенә кадәр югары басымлы газүткәргеч төзү;
- басымны югарыдан уртачага кадәр төшерү өчен газны редукцияләштерү пункты (ПРГ) урнаштыру;
- газны редукцияләштерү пунктыннан планлаштырыла торган БМК-1 блоклы модульле котельныйга кадәр урта басымлы газүткәргеч төзү»;

2.4. 5 пунктта «3 таблица» сүзләрен «4 таблица» сүзләре белән алыштырырга.

3. III «Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә» бүлегендә:

3.1. «4)» пунктта «коммерция биналары, амбулатория, физкультура-сәламәтләндерү комплексы» сүзләрен «күпфункцияле объектлар (шул исәптән физкультура-сәламәтләндерү комплексы белән) мәйданнары, поликлиника» сүзләре белән алыштырырга;

3.2. түбәндәге эчтәлекле 5 таблица өстәргә:

«5 таблица

**Чараларны гамәлгә ашыруның этаплары һәм максималь сроклары**

| **Капиталь төзелеш объектлары төрләре** | **Объектлар** | **Максималь сроклар** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру (җир кишәрлеген формалаштыру/ архитектура ягыннан проектлаштыру экспертиза)** | **Төзү*** | **Төзелеш территориясендә урнашкан гамәлдәге объектларны сүтү** |
| **1, 2, 3, 4 нче этаплар** | | | | |
| Торак билгеләнешендәге | 10366 кв.м мәйданда эчкә кертеп төзелгән торак булмаган билгеләнештәге биналар белән фатирларның гомуми мәйданы 121030 кв.м булган күпфатирлы торак йортлар | 2030 | 2034 | Территориядә сүтелергә тиешле объектлар юк |
| Социаль инфраструктура | 220 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре (2 объект) | | 2034** | |
| | 1224 урынга исәпләнгән мәктәп | | | |
| | Поликлиника | | 2034** | |
| Башка билгеләнештәге | Гомуми мәйданы 13114 кв.м булган күпфункцияле объектлар (шул исәптән физкультура-сәламәтләндерү комплексы белән) | | 2034 | |
| Инженерлык инфраструктурасы | Урнаштырыла торган объектлар өчен кирәкле инженерлык инфраструктурасы объектлары, шул исәптән котельный | | 2034 | |
| Транспорт инфраструктурасы | Урнаштырыла торган объектларга хезмәт күрсәтү өчен кирәкле урам-юл челтәре (этаплап башкарылырга мөмкин) | | 2034 | |
| | **5 нче этап** | | | |
| Торак билгеләнешендәге | Фатирларның гомуми мәйданы 40000 кв.м булган күпфатирлы торак йортлар | 2040 | 2044*** | Территориядә сүтелергә тиешле объектлар юк |
| Башка билгеләнештәге | Эчкә кертеп төзелгән паркинглар булган күпфункцияле объектлар, күпкатлы паркинглар, ачык парковкалар, хезмәт күрсәтү объектлары – 2 объект, 4 постка исәпләнгән янгын сүндерү депосы | | | |
| Инженерлык инфраструктурасы | Урнаштырыла торган объектлар өчен кирәкле инженерлык инфраструктурасы объектлары | | | |
| Транспорт инфраструктурасы | Урнаштырыла торган объектларга хезмәт күрсәтү өчен кирәкле урам-юл челтәре | | | |

* Төзелешкә рөхсәттә төгәлләштерелергә мөмкин.

** Дәүләт һәм муниципаль программаларны формалаштыру срокларын исәпкә алып төгәлләштерелергә мөмкин.

*** Тиешле шәһәр төзелеше документациясен эшләгәннән соң, аны нигезләгәннән соң, шулай ук торак төзелеше зонасын социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары белән тәэмин итү шарты үтәлгәндә».

---

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2023 елның 31 мартындагы 974 номерлы
карары белән расланган Вишневка торак
массивыннан көнчыгыштарак урнашкан
территорияне планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий,
границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры,
границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства

